РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**29.07.2021** **г.Чистополь** **№ 112**

Агачларны һәм куакларны кисүгә,
утыртуга, күчереп утыртуга, аларның
ябалдашларын формалаштырып кисүгә,
газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
Административ регламентын раслау турында

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы цифрлы трансформация проектларын гамәлгә ашыру буенча эш төркеме утырышының 2021 елның 14 июнендәге ШГ-12-186 номерлы беркетмәсе нигезендә, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Агачларны һәм куакларны кисүгә, утыртуга, күчереп утыртуга, аларның ябалдашларын формалаштырып кисүгә, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
2. Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Агачларны һәм куакларны кисүгә, утыртуга, күчереп утыртуга, аларның ябалдашларын формалаштырып кисүгә, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2021 елның 12 февралендәге 20 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садиковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
Комитет җитәкчесе И.Ф. Рәхимов